ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 78 от 29.10.2024

Татарстан Республикасы Иске Ильдеряк муниципаль берәмлегенен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җэмагать тынлаулары уздыруны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы нигезендә Аксубай муниципаль районы башлыгы Аксубай муниципаль районы Уставы белән карар чыгарды::

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Ильдеряк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча Иске Ильдеряк авыл җирлеге халкы катнашында җэмагать тынлаулары билгеләргә.

2. Җэмагать тынлауларын оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. М. Мингулов;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. И. Исләмов;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р. Р. Сарвартдинова;
- Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М. Ә. Габдрахманов;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгы С.М.Маклаков.

- 3. Җэмагать тынлауларын оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

- 4. Җэмагать тынлауларын үткәрү чорын - кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып җэмагать тынлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Җэмагать тынлауларын уздыру срогы бер айдан артмаска тиеш.

- 5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышулар башлану турында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсендә каралган хәбәр әзерләргә.

- 6.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.rn) һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (https://aksubayevo.tatarstan.ru/).
- 7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

-

Вакытлыча Аксубай муниципаль районы
башлыгы вазифаларын башкаручы : И.М. Загидуллин